## Күренекле милләттәшләребез

**Туймазы шәһәрендә гаҗәп үзенчәлекле иҗатчы — соңгы елларда татарның керамик сыннар, агачны уеп-юнып сурәтләр ясау сәнгатенә заманча яңарту төсе керткән рәссам Хәмит Латыйф яши. Дәрдмәндгә аһәңдәш шагыйрь дә ул. Русия Рәссамнар берлеге, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.**

**Күптән түгел Татарстан китап нәшриятында шома кәгазьгә басылган, эче-тышы бик килешле бизәлгән, исеме алтын хәрефләр белән язылган "Галәми гамь" дип аталган зур форматлы китабы дөнья күрде. Анда укып та, карап та туймаслык шигырьләр, сынлы сәнгать әсәрләре тупланып бирелгән.**

# Укып та, карап та туймаслык китап

Әле Хәмитнең түбәсе күккә тиеп йөргән көннәр. Казанга чакырганнар иде. Якташ шагыйрь Рәдиф Гаташ: "Мондый китап чыгару — әдәби-сәнгати тормышыбызда синең өчен зур танылу", — дип, күңеленә канат куеп кайтарган.

Бөтен гомерен татар сәнгате дөньясын өйрәнүгә багышлаган, күп хезмәтләр язган белгеч Розалина Шаһиева: "Хәзер Хәмит Латыйф чын мәгънәсендә бөек рәссам булып күзаллана. Нәфис сәнгать тарихында мәшһүр профессионалларның каләм әһелләренә тиңләшерлек язма мирас калдырулары атлаган саен очрамый. Татар җирендә Урманчедән кала икенче "җан сурәтен сүз сәнгате белән тоташтырган", Идел — Урал моңнарын бербөтен итеп өлгеләргә салган Хәмит Латыйф — бер күңел, бер олуг сәнгати җан. Аның күңеле тулы яңа аһәң, шигъри моң, җемҗем йолдыз" дигән изге фикердә тора.

Хәер, гаҗәп үзенчәлекле рәсемнәре, йөрәкне йолып алырлык шигырьләре "дөнья күзе"нә күренә башлагач та татарның танылган мәдәни-сәнгати затлары аны игътибар үзәгенә ала башлаган иде. СССРның халык рәссамы Әхмәт Лотфуллин өметле талант иясе иҗатына менә нинди бәя биргән: "Хәмитнең сынлы сәнгать өлкәсендәге уңышлары мине шатландыра. Бигрәк тә аның эшләрендә милли рух булуы сокландыра".

Язучы Шаһинур Мостафинның үз сокланулары: "Рәхмәт сине тудырган гали затларга, туган җиребезгә! Туймазыга барып без тагын олуг шәхес, чын иҗатчы Хәмит Латыйфны табып кайттык".

Хәмит белән якын дуслар булуыбызны белеп алгач, Туймазы шәһәренең танылган укытучысы өйгә килде һәм миңа бернәчә сорау бирде.

— Барлы гаиләдә, укымышлы ата-ана тәрбиясендә үскәндер, мөгаен?

— Түгел шул, тугач та үз көнен үзе күрә башлаган бала ул!

— Әллә ятимлектә үскәнме?

— Ятимнең дә ятиме!

Укытучы картның күңелендә шик калмасын өчен шагыйрь Газинур Моратның хатын укып ишеттердем: "Хәмит Латыйф төс-сурәтләргә сыеп бетмәгән күңелен шигырь итеп ак кәгазьгә сибә шикелле. Кече яшьтән үк дөньяның ачысын-төчесен татып, ятим үскән китек күңелле иҗатчы дөньядан аһәңлелек, җылылык, дәва эзли. Ләкин, ни хикмәт, адәм баласының дөньясы беркайчан да түгәрәк булмый шул..."

Нечкә хисле Хәмитнең "Искән җилгә каршы чыгып басыйм" шигырен укысаң, аның балачагы, үсмер еллары күз алдына килеп баса:

***Сарытауда куе камышлар бар,***<br>
***Камышлары гел дә сарыдан.***<br>
***Күзләремә көзге сагыш булып,***<br>
***Сарылары гүя сарылган.***<br>
***Сарыларын кая куйыйм икән?***<br>
***Суга салыр идем, су тирән.***<br>
***Тормыш юлы адаштырды кайчак,***<br>
***Сагышларым шуңа күп микән...***<br>
***Сагышлардан сарыланып кына***<br>
***Үтте гомер әрнеп, җан талып.***<br>
***Искән җилгә каршы чыгып басыйм,***<br>
***Сагышларны китсен җил алып.***

Тыйнаклыгы йөзенә чыккан Хәмит чын мәгънәсендә әдәбият, сәнгать кешесе. Ул үзен мактаганны яратмый, шуның өчен күңел кылларына бик сак кагылырга кирәк.

Халкыбызның көнкүрешендәге, гореф-гадәтләрендәге, мәдәниятебездәге җәүһәр бөртекләрен берәмтекләп туплаган гүзәл әсәрләре белән хәзер ул шәхес булып танылды.

Төс-башка сөйкемле ирнең күңел

гырьләренә күчкән. "Калган" шигырендә дә нәкъ шул хисләр бер-беренә үрелеп бирелгән.

***Үткәннәрдә үксез чагым калган,***<br>
***Калган инде бәгырь өзелеп.***<br>
***Өмет калган шыңшып, хисләр калган***<br>
***Көзге яңгырлардан түгелеп.***<br>
***Ал таңнарга ак томаннар аша***<br>
***Хәтер карап калган үрелеп.***<br>
***Теләк калган, әйтер сүзләр калган,***<br>
***Үксез елларыма күмелеп.***<br>
***Яшьлекләрем, сагышларым калган***<br>
***Хәтер тирәгенә бәйләнеп.***<br>
***Үткәннәрдән, их, бер килер идем,***<br>
***Иртәнге төш кебек әйләнеп.***

Инде ир уртасын узган Хәмит бүген дә "замана фәкыйрьләре" тормышы белән яши. Моның сәбәбе — эти нигезеннән мирас милке калмау, балачактан ук төрле урыннарда, төрле кулларда кагылып-сугылып йөрүләр...

Бу хакыйкатьне ул үзе дә яшерми:

— Бәхетле-бәхетсез язмышым өчен беркемгә дә үпкәләмим. Чөнки кешенең күрәчәге туганда ук маңгаена языла.

Пермь өлкәсенең Губаха шәһәрендә туганмын. Эти белән әни күмер шахтасында эшләгән. Мин биләүдә чакта этиемнең туган ягы Буләр авылына (Илеш районы) кайтканбыз. Җиде айлык чагымда әнием дөнья куйган. Мине карап үстерергә кеше булсын, дип, этием (Нәҗип исемле иде) ике балалы Дөһедия апага йортка кергән. Биш яшемә кадәр аның тәрбиясендә үскәнмен.

— Йортка кермәк — җан бирмәк, диләр. Үги ана кулында бер дә кадер булмагандыр инде?

— Киресенчә! Шушы кыска гына вакыт эчендә Дөһедия апа миңа ана җылысы биреп өлгергән. Аңа атап язган шигырем

***Ап-ак кардай чәчләреңне***<br>
***Дала җиле тарый микән?***<br>
***Үги ана — изге ана, дип,***<br>
***Балаларың таный микән?***<br>
***Синең улың булмасам да,***<br>
***"Улым", дип кала идең.***<br>
***"Шул баланы ташлама", дип,***<br>
***Ходайга бага идең.***<br>
***Җил-давылда гаҗиз калсам,***<br>
***Хәлем бетеп, җиргә аусам,***<br>
***Җирдән тоеп җан җылыңны,***<br>
***Шуннан хәлләр ала идем.***<br>
***Дөнья гамен читкә куеп,***<br>
***Сагынып сиңа бара идем.***<br>
***"Беркемең дә юк, балам", дип,***<br>
***Күз яшьләрең тама иде,***<br>
***Өзгәләнеп кала идең.***<br>
***Кочагыңа алып җанымны —***<br>
***Шәфкатьләрең яба идең.***<br>
***"Ач йөрмә", дип ак күмәчне***<br>
***Биштәремә сала идең.***<br>
***Ходаеңа баккан җаның***<br>
***Әүлиядәй балкый микән?***<br>
***Ятимнәрне, сабыйларны***<br>
***Афәтләрдән саклый микән?!***

Унөч яшем тулып кына торган көннәрдә этием вафат булды. Менә шуннан соң китте кагылып-сугылып йөрүләр...

Бер кичне йокымсырап ята идем, Тәңре колагыма: "Йөз суларыңны түгеп кеше кулларында интегеп йөрмә. Сиңа тумыштан ук акыл, сәләт бирелгән. Үзеңне яшәтергә җитәрлек һөнәр үзләштерсәң, җаның тынычлап калыр. Тик хезмәт җимешләреңнең тәмен, һөнәреңнең кадерен бел, кешеләргә тәмле телле, мәрхәмәтле бул!" дип пышылдаган кебек тоелды. Тәңренең бу сүзләрен эти-әнием киңәшедер дип аңладым.

Үксез бала үз кендеген үзе кисәр, диит. Тәвәккәллек итеп, Уфага киттем. Музыка училищесының сынлы сәнгать бүлегендә укып йөрим. Үз хәлемне үзем беләм: өс-башта — иске генә киемнәр, аякта — тузып беткән ботинка...

Нишләтәсең бит инде, ятимлек, фәкыйрьлек күп бәхетләрдән мәхрүм итте. Әмма өметле талант икәнемне сизеп йөрүчеләр булган икән. Шундый изге күңелле кешеләрнең ярдәме белән Мәскәүдә укырга чакырылдым. Тик йорт-җирсез егетнең анда китү мөмкинлеге булмады.

"Алдыңда — ышанычың, артыңда таянычың булсын" дип борынгылар белеп әйткән. Ә минем кемем бар? Яр Чаллы шәһәренә эшкә чакырылып баргач кына бераз җиңеллек тоеп яши башладым.

Халыкчан талант иясе Хәмит хак сүзләр сөйли: нигә кулыңнан гөлләр сибелми икән, ишекләр шакый-шакый алдан йөрердәй, ярдәм итәрдәй кешең булмаса, бүгенге тормышта сине беркем дә санга сукмый. Тик Туймазыда яши башлагач кына Хәмит фатирлы булды, бөтен сәләтен эшкә җигеп, әдәби-сәнгати иҗат белән ныклап шөгыльләнә башлады.

...Йөрәк каны белән сугарылган шигырьләр, күз нурлары түгә-түгә ясаган рәсемнәр... Милли сәнгатебезгә җанытәне белән бирелеп хезмәт итүче Хәмит Латыйф — бүген дә иҗат диңгезендә колач салып йөзә. "Галәми гамь" — аның өчен һәйкәл булырлык китап ул!

Бу язманы Хәмитнең үзе яраткан шигырь юллары белән тәмамлыйбыз:

***Авыл капкасыннан атлар узды,***<br>
***Атлар белән китте абыйлар.***<br>
***Читән башларыннан карап калды,***<br>
***Кулын болгап үксез сабыйлар.***

**Вәли ҖИҺАНШИН.**